| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ИВАНОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИВАНОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2020 елның 12 февраленнән № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2015 елның 20 ноябрендәге 12 номерлы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Лөниногорск муниципаль районының "Ивановка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегө территориясендә төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм тәртипкә бердәм таләпләрне билгеләү максатларында Ивановка авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен тезекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

287 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«287. Җир асты коммуникацияләрендә аварияләр бетерелгәннән соң, юллар, тротуарлар өслекләрен торгызу эшләр тәмамланган мизгелдән соң, 287.1 каралган очраклардан тыш, 10 көнлек сроктан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 287.1 һәм 287.2 пунктлар өстәргә:

287.1. Җир эшләре тәмамланганнан соң, эшләр җитештерүче юл өслекләрен торгызу эшләрен башлап җибәрергә тиеш: урамнарның аркылы өзелгән урыннарында - тәүлек дәвамында;

машина юлының озынча өзелү урыннары - 5 кен эчендә;

җирле юлларны, тротуарларны, тулы кыйммәтле юлларны казу урыннары газоннар - 10 көннән дә соңга калмыйча.

Аны торгызу алдыннан асфальт өслекнең кырыйлары фрөза белән эшкәртелергә тиеш.

287.2.Кышкы чорда, һава шартлары белән һәм температура режимы белән эшләү технологиясен үтәү уңайсыз булуга бәйле рәвештә, җир эшләре тәмамланмаган очракта, эш җитештерүче түбәндәгеләргә бурычлы: җир эшләрен җитештерү зонасында территорияне тәртипкә китерү буенча кирәкле чаралар үткәрергә;

юллар (тротуарлар) участокларында, тезекләндерү элементларын тулысынча торгызу мизгеленә кадәр,

җир эшләре барышында бозылган җәяүлеләрнең һәм транспортның хәвефсез хәрәкәтен тәэмин итәргә.»

2. Әлеге карарны Ивановка авылы, Яшьлек урамы, 5, Аккүл авылы, Колхоз урамы, 16Б, Медведка авылы, Дорожная урамы, 32, Михайловка авылы,Үзәк урам, 4 нче йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларда игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) “Авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлегә карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
"Ивановка авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе А.П. Бодряева